| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2 ноябрь, 2022 ел № 17/6

Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2019 елның 23 маендагы 31/6, 2020 елның 6 февралендәге 36/5, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/13, 2020 елның 17 ноябрендәге 2/3, 2021 елның 16 февралендәге 5/7, 2021 елның 27 декабрендәге 11/6, 2022 елның 25 февралендәге 13/8, 2022 елның 13 апрелендәге 14/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 17 пунктта «11 498» саннарын «11 958» саннарына алыштырырга;

2) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесеннән тыш, аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициентлары:

| Вазыйфа исеме | Арттыру коэффициенты (вазыйфаи окладның проценты) | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 | 26 906 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 | 23 916 |
| Бүлек башлыгы | 1,65 | 19 731 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,55 | 18 535 |
| Баш белгеч | 1,4 | 16 742 |
| Әйдәүче белгеч | 1,17 | 13 991 |
| I категорияле белгеч | 1,12 | 13 393 |
| II категорияле белгеч | 1,1 | 13 154 |
| Белгеч | 1,08 | 12 915»; |

3) 21.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.1 «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Җитәкче | 29 780 |
| Җитәкченең беренче урынбасары; җитәкче урынбасары | 28 066 |
| Бүлек башлыгы | 21 960 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 19 765 |
| Баш белгеч | 17 997 |
| Әйдәүче белгеч | 16 390»; |

4) 21.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.2 Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициенты:

| Вазыйфа исеме | Коэфффициент | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада басу бюросы мөдире, күчермәләр ясау - күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, секретарь-стенографист, машинист, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче секретаре, таксировщик, участок мастеры (шул исәптән өлкән мастер) | 1,0 | 11 958.». |

2. Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре өчен гамәлдә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев